СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

“09” октябрь 2019 ел № 35

Яңа Кишет авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

**Яңа Кишет авыл җирлеге**

**Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга яраклаштыру максатынннан, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына таянып, Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2014 елның 27 октябрендәге 97.1 номерлы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карары белән расланган (2015 елның 30 июнендәге 16 нче, 2015 елның 26 октябрендәге 7 нчы, 2016 елның 1 ноябрендәге 17нче, 2017 елның 11 маендагы 5 нче, 2018 елның 8 маендагы 3нче, 2018 елның 7 сентябрендәге 6 нче номерлы үзгәрешләр белән) Яңа Кишет авыл җирлеге Советы Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне расларга:

**1) 5 статьяда:**

**-1 нче өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым җыю), транспорт белән чыгару эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

**-1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:**

«20) Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үзирекле төзелгән корылманы сүтү, үзирекле төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү;»

**2) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:**

«6 статья. Җирле үзидарә органнарының җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре белән бәйле булмаган мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәге хокукка ия:

1) Җирлек музейлары булдыру;